**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 27 ноябрь № 898

г. Казань

Ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар өчен «Мәрхәмәт» 74 нче балалар йорты» дәүләт бюджет учреждениесен ябу һәм «Чаллы шәһәренең Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларны гаиләләргә урнаштыруда ярдәм итү, алыштыручы гаиләләрне әзерләү һәм аларга булышлык күрсәтү үзәге» дәүләт бюджет учреждениесен төзү турында

Россия Федерациясе Президентының «Ятим балаларны һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларны яклау өлкәсендә дәүләт социаль сәясәтен тормышка ашыру буенча кайбер чаралар турында» 2012 ел, 28 декабрь, 1688 нче Указын үтәү йөзеннән, шулай ук ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларны гаиләләргә урнаштыруны үстерү буенча дәүләт сәясәтен камилләштерү һәм чаралар комплексын алга таба гамәлгә ашыру, интернат учреждениеләре челтәрен карап тотуга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарын оптимизацияләү һәм учреждениеләр мөлкәтеннән нәтиҗәле файдалану максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 423814, Татарстан Республикасы, Чаллы шәһәре, Әхмәтшин урамы, 107/28 (58/08) йорт адресы буенча урнашкан Ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар өчен «Мәрхәмәт» 74 нче балалар йорты» дәүләт бюджет учреждениесен (алга таба – Балалар йорты) ябу турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Гамәлгә куючы вазыйфаларын һәм вәкаләтләрен башкарган Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына:

14 көн эчендә:

Балалар йортын ябу комиссиясе составын расларга;

Россия Федерациясе Граждан кодексы нигезендә Балалар йортын ябу тәртибен һәм вакытларын билгеләргә;

өч көн эчендә теркәүче органга Юридик затларның берәм дәүләт реестрына кертү өчен Балалар йорты ябылу процессында булу турында мәгълүматлар тапшырырга;

ябу комиссиясе тарафыннан законнар белән күздә тотылган тиешле чараларның гамәлгә ашырылуын тәэмин итәргә, шулай ук Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә ябылу нәтиҗәсендә эштән азат ителә торган хезмәткәрләргә гарантияләр һәм компенсацияләр бирүне тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Чаллы шәһәренең Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларны гаиләләргә урнаштыруда ярдәм итү, алыштыручы гаиләләрне әзерләү һәм аларга булышлык күрсәтү үзәге» дәүләт бюджет учреждениесен (алга таба – Үзәк) төзү турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

4. Үзәкне гамәлгә куючы вазыйфаларын һәм вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы башкара дип билгеләргә.

5. Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларны гаиләләргә урнаштыруда, алыштыручы гаиләләрне әзерләүдә һәм аларга булышлык күрсәтүдә, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар өчен оешмаларны тәмамлаучыларның социаль (интернаттан соң) адаптациясен оештыру һәм тәэмин итүдә ярдәм күрсәтү Үзәкнең төп эшчәнлек максаты дип билгеләргә.

6. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына:

60 көн эчендә Үзәкнең уставын расларга һәм аны дәүләт теркәвенә алуны гамәлгә ашырырга;

уставы белән күздә тотылган төп эшчәнлек нигезендә Үзәккә дәүләт йөкләмәсен ел саен билгеләнгән тәртиптә расларга;

Үзәкнең уставын раслаганнан һәм дәүләт теркәвенә алганнан соң 10 көн эчендә оператив идарә хокукында дәүләт мөлкәтен беркетү өчен кирәкле документларны, шул исәптән күчемсез милек объектларына техник документларны, шулай ук җир кишәрлеген рәсмиләштерү өчен документларны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына кертүне тәэмин итәргә.

7. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына,Үзәкне теркәгәннән соң:

Үзәк уставын дәүләт теркәвенә алганнан соң һәм аны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы керткәннән соң 30 көн эчендә Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен, шул исәптән элек Балалар йортына беркетелгән, Үзәк эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәкле аеруча кыйммәткә ия күчмә милекне оператив идарә хокукында Үзәккә беркетергә;

дүрт ай эчендә Үзәккә беркетелә торган күчемсез милек объектлары урнашкан 423814, Татарстан Республикасы, Чаллы шәһәре, Әхмәтшин урамы, 107/28 (58/08) йорт адресы буенча 16:52:040301:0008 кадастр санлы җир кишәрлеген Үзәккә даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукында бирүне тәэмин итәргә.

8. Үзәкнең дәүләт йөкләмәсен үтәвен финанслар белән тәэмин итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренә карата дәүләт йөкләмәсен формалаштыру һәм аның үтәлешен финанслар белән тәэмин итү тәртибе турында» 2010 ел, 29 апрель, 308 нче карары

нигезендә, Татарстан Республикасы бюджетында әлеге максатларга күздә тотылган акча чикләрендә гамәлгә ашырыла, дип билгеләргә.

9. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәгенә, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә, барлык ябу чараларын үткәргәннән соң, Үзәк уставын раслаганнан һәм дәүләт теркәвенә алганнан соң 60 көн эчендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләре башкаруга) норматив чыгымнарны һәм Үзәк мөлкәтен карап тотуга норматив чыгымнарны эшләргә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына раслауга кертергә.

10. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законына тиешле үзгәрешләр кертү турында билгеләнгән тәртиптә тәкъдимнәр кертергә.

11. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\898.doc